КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 август г.Казань № 780

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 июнь, 502 нче, 2022 ел, 11 март, 317 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

«г» пунктчасында «яисә 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә хайваннар белән эш итү» сүзләрен төшерергә;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре нигезендә кирәкле башка чаралар»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин